

Бәйрәмне vткәрv идеясе 2004 елда Ботендонья ижтимагый форумнарында барлыкка килгән. 2005 елда «Чәй коне»н ел саен 15 декабрьдә билгеләп vтv турында Карар кабул ителгән. Шулай (рәсемдә) Ләмберә районы Аксён авылы мәдәният йорты хезмәткәрләре бергәләп Халыкара чәй конен бәйрәм итәләр.
Халыкара чәй коне хокvмәтләрнен игътибарын чәй сату проблемаларына, чәй житештерvчеләренен кулланучыларны жәлеп итv максатыннан билгеләп vтелә.
Шулай ук чәйнен ни дәрәжәдә файдалы һәм тәмле булуын кvрсәтелә. Хәзер бу бәйрәмне чәй житештерvче илләрдә генә тvгел, ә Европада, Россиядә дә билгеләп vтәләр. Бу конне кvп кенә илләрдә ярминкәләр оештыралар, чәйнен яна сортларын тәкъдим итv һәм дегустация уза.
Татарларда чәй эчv йоласы борынгыдан килә. Анын бик кызыклыларын татар классиклары Утыз Имәни һәм Каюм Насыйри әсәрләреннән укып белергә була. Мисалга, татарларда чәй эчv вакытында авыз ителvче тәм-томнарнын тулы системасы бар. Соттән пешерелгән ризыкларнын бик оригиналь рецептлары билгеле. Тагын бер кызыклы факт, бездә сот чәйнен vзенә салынса, инглизләрдә чәйне соткә салалар. Моннан тыш, дару vләннәре кушу гадәте татарларда бик кин жәелгән. Татарлар чәйне бик яратып эчә. Без бу эчемлеккә жиләк-жимеш салып, тәмле кайнатмалар, бал белән эчәргә яратабыз. Чәй янына торле-торле татлы камыр ашлары куела. Татарлар чәйне ойдәгеләр, кунаклар белән бергәләп, сусауны гына бастырмыйлар, аралашу очен дә эчәргә яраталар.
Татарлар очен чәй - башка халыкларнын кебек vк кунакчыллык символы.
Бу бәйрәмнен барлыкка килv тарихына кvз салыйк. Чәй тарихы инде биш мен елдан артык исәпләнә, әмма бу яраткан эчемлекне кем ачты, тогәл билгеле тvгел. Чәй, эчемлек кебек, Кы-тайнын икенче императоры Шен Нунг тарафыннан ачылган дип санала.
Риваять буенча, император походларынын берсендә, кайнап торган котелдагы суга учактан ерак тvгел vсvче чәй агачынын яфраклары эләккән. Император, шул суны эчкәч, анын гадәти булмаган хуш исе һәм тәме шаккатырган һәм мондый эчемлекне киләчәктә дә кулланырга теләгән. Нәкъ менә Кытайдан заманча чәй исеме дә килгән дип саныйлар. Империянен Коньяк провинцияләрендә аны - «te», ә тоньяк провинцияләрендә - «cha» дип атыйлар. Шуна бәйле рәвештә, безгә билгеле булган сvзләр - инглиз «tea» һәм рус «чәй» сvзләре барлыкка килгән дип саныйлар. Кытайда кvп кенә чәй яратучылар эчемлекләренә суган, имбирь, тәмләткечләр яки әфлисун остиләр.
Россиялеләр чәй белән 1638 елда таныштылар. Бу танышу, башка илләрдәге кебек vк, барын-нан да элек, дипломатик элем-тәләр һәм этикет ярдәмендә башлана. Торле халыклар мәдә-ниятендә әлеге эчемлекне кулланунын vз традицияләре һәм

кагыйдәләре бар.
Россиядә, иске гореф-гадәтләр буенча, чәйне самавырларда пешерәләр, шул ук вакытта чәй очен чынаяклары зур була. Чәйне гадәттә бублик, пирог, кайнатма, бал белән эчкәннәр. Бvген - кем нәрсә белән эчәргә тели, шунын белән эчә.
Шул ук вакытта чәй планетада ин популяр тонуслы эчемлек булып кала бирә. Табиблар чәй иммунитетны арттыра, канда холестерин дәрәжәсен киметә, шулай ук яман шешкә каршы һәм антиоксидантларга каршы хәрәкәтләргә ия, диләр. Алар кvбрәк чәй эчәргә киңәш итә, бигрәк тә сезонлы салкын тию авырулары вакытында. Моннан тыш, чәй йорәк-кан тамырлары авыруларынын vзенчәлекле профилактикасы булып тора, чонки анда булган файдалы матдәләр кан тамырларын чистартып кына калмыйча, аларнын эластиклыгын да арттыра. Яшел чәй билгеле бер дәрәжәдә Альцгеймер авыруына каршы тора, боерләрдә ташлар барлыкка килvне тоткарлый, сояклэрне ныгыта, диләр.

**Н.ХӘЛИЛ**